ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октября 2025 ел № 1019

**Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, 2010 елның 27 июлендәге “Җылылык белән тәэмин итү турында” 190-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә үзәкләштерелгән, өзлексез җылылык белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Таткоммунэнерго” РҖБ” АҖен Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешма итеп билгеләргә.

2. Гарантияләүче оешма “Таткоммунэнерго” РҖБ” АҖнә Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә урнашкан абонентларны, шулай ук җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган капиталь төзелеш объектларын законда билгеләнгән тәртиптә җылылык белән тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты Аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.А.Галимуллин